Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Бишмунча авыл Советы

КАРАРЫ

14 декабрь 2023 ел № 92

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмә тмуниципаль районының 2013 елның 25 ноябрендәге72 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, Россия Федерациясе Салым кодексының 31 бүлеге икенче өлеше, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге Уставының 28 статьясы нигезендә,

Бишмунча авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл җирлеге территориясендә җир салымы турында» Татарстан Республикасы Әлмәт 72 номерлы карарына (Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Бишмунча авыл Советының 2014 елның 19 ноябрендәге 100 номерлы, 2015 елның 5 маендагы 117 номерлы, 2020 елның 12 маендагы 92 номерлы, 2020 елның 18 ноябрендәге 4 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (күчемсез милек объектына туры килә торган, торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексының инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган җир кишәрлекләреннән тыш) яисә эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш) 0,3 процент.

2.Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Бишмунча авылы, Совет ур., 57а йорт, Кама-Елга авылы, Кама-Елга ур., 26 а йорт, Ак Чишмә авылы, Ак-Чишмә ур.,1 йорт, Бахчасарай авылы, Җиләкле ур., 1 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә һәм 2024 елның 01 январеннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуныавыл Советы башлыгына йөкләргә.

Бишмунча авыл җирлеге башлыгы
вазифаларын башкаручы М.Ф.Илалов